**РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ЖИТӘКЧЕСЕ**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740
Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740
Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
17.09.2019г.

КАРАР
№ ПР-192

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы буенча 2019/2020 елга җылыту сезоны башлану турында

Көзге-кышкы сезон башлану белән бәйле рәвештә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Җылылык белән тәэмин итү турында» 27.07.2010 ел, № 190-ФЗ Федераль законга, Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының «Җылылык чорына әзерлекне бәяләү кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 12 мартындагы 103 номерлы боерыгына таянып, мәктәп, мәктәпкәчә, медицина учреждениеләрендә температура режимын үтәү һәм нормаль шартлар тудыру өчен, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1.Җылылык белән тәэмин итүче оешмалар җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

1.1. Актаныш муниципаль районы территориясендә социаль, мәдәни һәм көнкүреш билгеләнешендәге объектлар өчен 2019-2020 елгы җылыту сезоны башлануны, тышкы һаваның уртача тәүлеклек температурасы 5 тәүлек буена +8° С һәм аннан да түбәнрәк булган очракта, 2019 елның 17 сентябреннән башлап билгеләргә.

1.2.Социаль өлкә объектларын җылылык белән тәэмин итү белән янаучы авария һәм авария хәлендә булган очракларда диспетчерлык һәм авария хәлендәге хезмәтләрнең ышанычлы һәм өзлексез эшләвен тәэмин итәргә, кичекмәстән Актаныш муниципаль районы Бердәм хәбәр итү һәм Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә хәбәр итәргә.

1.3.Мәгариф, мәдәният бүлекләре җитәкчеләренә, Актаныш ЦРБ баш табибына җылылык энергиясе белән тәэмин итеп торучыларга, кышкы шартларда эксплуатация объектларының әзерлеге турындагы документацияне кушып, җылылык җибәрү өчен гариза бирергә тәкъдим итәргә.

2. Предприятие, учреждение җитәкчеләренә үз объектларына җылылык җибәрү буенча тиешле чаралар күрергә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Башкарма Комитет җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы — Л. Ф. Нурлыева

С. З. Газизҗанова